Галим, З. Миләүшә Имамовага - роль, алка һәм алкышлар / З. Галим // Шәһри Чаллы. – 2022. – №85 (23 ноябрь). – Б. 3.

# Миләүшә Имамовага - роль, алка һәм алкышлар

## Юбилей кичәсе

**Зөлфия** Галим

**Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Имамованың 50 яшьлек юбилей кичәсе узды.**

Дөресрәге, юбилей уңаеннан Аяз Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Болан» спектакленең премьерасы булды.

Спектакль алдыннан талантлы артистны Чаллы мәдәният идарәсе башлыгы Румил Кәрәмиев, ТР Театр әһелләре берлеге җитәкчесе, Г. Камал театрының баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев, Татарстан язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе, язучы Фаил Сафин, Миләүшә Имамованың театр училищесындагы сабакташлары, теркемдәшләре һәм Минзәлә татар дәүләт драма театры артистлары гомер бәйрәме белән котладылар.

Фәрит Бикчәнтәев актрисага үзенчәлекле бүләкләр тапшырды. Миләүшә Имамова Казан театры училищесының беренче курсында укыганда ук Г.Камал театрында уйнаган.

- «Оҗмах балалары»ндагы ролең истә калган. Сине театр берлеге җитәкчесе һәм Г.Камал театры коллективы исеменнән котлыйм. Рольләрең булып торсын. Артистка Люция Хәмитова: «Талантлы, кояш кебек якты Миләүшәгә кояш формасындагы алкаларымны бүләк ит эле», - диде. Бүләкне кабул ит, - диде Фәрит Рәфкатович.

Чаллы театры исә юбилярга «Болан» спектаклендәге Мәсрүрә ролен бүләк итте. Тамашачылар сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов куйган спектакльне җылы кабул иттеләр.

Сүз уңаеннан, әлеге спектакльдә Алсу Хәбетдинованың роле искиткеч, рәхәтләнеп карый торган килеп чыккан. Алсу герое тормышы белән яши.

Драмада катнашкан калган артистлар да үз рольләрен тамашачы күңелендә калырлык итеп уйнадылар. Спектакльгә музыканы композитор Гөлназ Закирова язган. Заманча технологияләр куллану нәтиҗәсендә театр репертуарында матур спектакль барлыкка килде. Аңа язучы, драматург Аяз Гыйләҗевнең хатыны Нәкыя Гыйләҗева да югары бәя бирде